ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 30 Бәйрәкәтамак ав. 28 декабрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2018 елның 28 мартындагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 182 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2018 елның 17 октябрендәге «Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында"гы 940 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 10 санлы карары белән расланган (17.12.2018 №28 редакциясендә) үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәгеләрне үзгәрешләр кертергә:

«муниципаль берәмлекләр башлыкларына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына хезмәт хакын түләү" 1 бүлегендәге 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата бүләк, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә, муниципаль хокукый актлар нигезендә премияләр түләнә. Шул ук вакытта айлык акчалата бүләкне түләү өлешендә хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме елына 6,72 айлык акчалата бүләк нормативыннан артып китә алмый. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә күләме Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 3 пункты белән билгеләнгән күләмнәрдән артып китә алмый. Шул ук вакытта чыгымнар күләме елына өч айлык акчалата бүләк тәшкил иткән нормативтан артып китә алмый.».

2. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 декабрендәге «Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 10 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 28 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru,

Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында да Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча эләргә: www.yutaza.tatar.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен даими бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әһлиева